Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең
Түбән Абдул торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

19 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 19 ноябре 15 сәгать 00 минутта, 2021елның 19 ноябре 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә : «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигь булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәләндерү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү?» сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 495 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 286 кеше, бу 57,8% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 286-сы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигь булган яшәүчедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Түбән Абдул авылы, Ленин урамы,92 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Юнысов